«Күбәләк» 15 нче балаларның танып-белү-сөйләм үсешен өстенлекле гамәлгә ашыручы гомумүстерешле балалар бакчасы» муниципальавтономияле мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе

Яр Чаллы шәһәренең «Күбәләк»
15 нче балалар бакчасы» МАМББУ
мөдире боерыгы
нигезендә гамәлгә кертелде
№ 258 28 август 2024 ел.

РАСЛЫЙМ
Яр Чаллы шәһәренең «Күбәләк» 15 нче
балалар бакчасы» МАМББУ мөдире
__________________Л.Р.Бычок
« 28 »август 2024 ел.

Педагогик киңәшмәдә каралган һәм расланган.
Беркетмә № 1
« 28 » август 2024 ел.

# Белем бирү эшчәнлеге буенча эш программасы
# Икенче кечкенәләр татар төркеме №3 “Әкият”

Мәктәпкәчә белем бирүнең федераль белем бирү программасын, федераль дәүләт белем бирү стандартын күздә тотып, укыту методик комплектларга нигезләнеп төзелде
(2024-2025 нче уку елы)

Эшләде:
Тәрбияче: Фардиева Ландыш Мөнәвир кызы

Яр Чаллы шәһәре, 2024 ел.

## Эчтәлек

1. **Максатчан бүлек.**

   1.1. Аңлатмалы язу.

   1.2. 3- 4 яшьлек балаларның шәхси һәм яшь үзенчәлекләре.

   1.3. Төркем эшчәнлегенең төп юнәлеше.

2. **Эчтәлек бүлеге**

   2.1.Комплекслы- тематик планлаштыру.

   2.2. Гаилә белән үзара бәйләнеш.

   * Гаилә белән үзара бәйләнеш принңиплары.

   * Ата- аналар белән үзара бәйләнеш формалары.

   * Гаилә белән үзара бәйләнеш буенча эшләү планы.

   2.3 Җәмгыять белән хезмәттәшлек.

3. **Оештыру бүлеге.**

   3.1.Материаль-техник кулланма.

   3.2. Программа һәм методика белән тәэмин итү.

   3.3.Үстерешле предметлы тирәлек.

   3.4. Сәламәтләндерү чаралары.

   3.5. Традиңион вакыйгалар, бәйрәмнәр, чаралар.

**Кушымта**

## 1.1.Аңлатма язуы

“Об образовании в Российском Федерации” Федераль канунына нигезләнеп, Россиядә мәктәпкәчә белем бирү гомуми белем бирүнең беренче дәрәҗәдәге статусын алды. Белем бирү программаларын тормышка ашырганда мәктәпкәчә белем бирү ФДББС “Об утверждении федерального государственного образовательного стандарта дошкольного образования» (Приказ Министерства образования и науки Российской Федерации № 1155 от 17 октября 2013 года), нигезендә җайга салына.

Эш программасы Федераль белем бирү программасына **(ФББП (ФОП)** нигезләнеп төзелде, максат һәм бурычларны, көтелгән нәтиҗәләрне, белем бирү процессын оештыруны билгели.

Аның төп бурычы- мәктәпкәчә яшьтәге балаларның тулы кыйммәтле яшәеше өчен уңайлы шартлар тудыру, шәхес культурасының нигезле җирлеген формалаштыру. Программаны төзегәндә белем бирү үсешендә хәзерге заман халыкара тенденцияләр исәпкә алынды:

- балада әйләнә-тирәгә яңа караш формалаштыру;
- практикада белем бирүнең төп юнәлешләрен (экологик, экономик, социаль) тормышка ашыру;
- эшчәнлектә балаларның шәхси тәҗрибәләрен (көнкүреш, культура, социаль, әхлакый) актив куллану;
- балалар инициативасын, белемнә омтылышын, мөстәкыйльлеген үстерү;
- белем бирү процессын нәтиҗәле итү өчен төрле эшчәнлекне берләштерү (интегральләштерү)
- балаларның уенга, куркынычсызлыкка, уңайлы әйләнә-тирәгә хокукын саклау;
-сыйфатлы белем алуга мөмкинлек тудыру;
- балаларны социумга актив кертү.

Эш программасын тормышка ашыру срогы- 1 ел

## 1.2. 3-4 яшьлек балаларның яшь үзенчәлекләре.

3-4 яшьлек баланың карашлары акрынлап гаилә чикләрен үтеп чыга башлый. Ситуацияләрдән тыш аралашулар барлыкка килә. Олы кеше аның өчен гаилә әгъзасы гына түгел, ә аерым иҗтимагый функция башкаручыга әйләнә. Баланың да иҗтимагый функция башкарасы килү теләге аның реаль мөмкинлекләре белән каршылыкка китерә. Бу каршылык мәктәпкәчә яшьтәгеләр эшчәнлегенең төп төре булган уен аша чишелә.

Шартлылык уенның төп үзенчәлеге булып тора: бер төрле предметлар белән эш-хәрәкәтләр аларның башка предметлар белән икенче эш-хәрәкәтләргә каравын күз алдында тота. Кече яшьтәгеләр 1-2 рольле яки гади, җыйнак сюжетлы уеннар белән канәгатьләнәләр. Бу яшьтә кагыйдәле уеннар формалаша гына башлый әле.

Баланың сурәтләү эшчәнлеге аның предмет турында күзаллауларына бәйле. Бу яшьтә ул әле формалаша гына. График образлар бик гади, ярлы. Кайбер балаларның сурәтләрендә детальләр җитешми. Балалар инде төсләрне куллана беләләр.

Кул чуклары хәрәкәтләрен үстерүдә эвәләүнең әһәмияте гаять зур. Кече яшьтәгеләр олылар җитәкчелегендә эвәләп гади предметлар ясарга сәләтле.

Кисеп ябыштыру кабул итүчәнлекне үстерүгә уңай йогынты ясый. Бу яшьтә балалар кисеп ябыштыруның иң гади төрләрен эшли алалар. Бу яшьтәгеләр өчен конструкцияләү эшчәнлеге күрсәтелгән үрнәк буенча һәм үзләре уйлап тапкан гади корылмалар төзүдән гыйбарәт.

Кече мәктәпкәчә яшьнең ахырына балалар 5 тән артык предмет формаларын һәм 7 дән артык төсне кабул итәргә, предметларны зурлыклары буенча аерырга,балалар бакчасы бинасында да ориентлашырга сәләтлеләр.

Аларның хәтере һәм игьтибарлылыгы үсә. Күрсәтмәле-тәэсирле фикер йөртү сәләте үсеше дәвам итә.

Бу яшьтә иҗади күзаллау сәләте үсә башлый. Балалар уен вакытында бер төрле объектларны башкаларын алыштыручылар сыйфатында кулланалар.

Балалар арасындагы мөнәсәбәтләр бигрәк тә уен эшчәнлегендә ачык чагыла. Алар күбрәк бергәләшеп түгел, ә янәшә уйнауны өстен күрәләр. Низаглар күбесенчә уенчыклар арасында килеп чыга. Баланың төркемдәге яшьтәшләре арасындагы дәрәҗәсе нигездә тәрбияче фикере белән билгеләнә.

Бу яшьтә балалар аңлы рәвештә үз тәртипләре белән идарә итә белмиләр, күбесенчә баланың тәртибе ситуациягә бәйле. Шуның белән берррәттән, балаларның, олылар әйтүе буенча, нииндидер теләкләрен чикләү очраклары да күзәтелә. Үз-үзен бәяләү сыйфаты үсә башлый, бу күп очракта тәрбияче фикеренә нигезләнгән була. Җенси аерымлыкларның да үсеше күзәтелә. Ул бигрәк тә уенчыклар һәм уен сюжетларын сайлаганда (кызлар-курчак, малайлар машина сайлый) ачык чагыла.

## 1.3. Төркем эшчәнлегенең юнәлеше.

Бүген җәмгыятьтә катлаулы социаль-экономик процесслар бара, белем бирүнең кыйммәтләре һәм максаты тамырдан үзгәрә. Балаларга белем бирүнең бөтен өлкәләрендә дә актив, иҗади, үзен үзгәртергә әзер торучы шәхес тәрбияләү таныла. Балаларның шәхси һәм социаль мөнәсәбәт позициясен күздә тотып, аларны мәктәпкә әзерләүдән күчү, мәктәпкәчә белем бирү нәтиҗәләренең күзаллавын үзгәртергә булыша. Нәтиҗәлелек: мәктәпкәчә яшьтәге балаларда кызыксынучанлык, активлык, мөстәкыйльлек сыйфатларын формалаштыра; ялгышларны уңышсызлыкларны җиңеп чыгарга әзерлек, яңа белем алырга, стандарт булмаган ситуацияләрдән чыгу юлын эзләргә

омтылыш тудыра; үзе сайлаган эшкә җаваплылык, командада эшли белү, үзенә, башкаларга, җәмгыятькә, әйләнә-тирәгә ихтирамлы караш, кайгыртучнлык тәрбияли. Болар барысы да баланы мәктәпкә әзерләп кенә калмый, ә хәзерге җәмгыятьтә уңышлы мөстәкыйль эшләү өчен нигез булып тора. Билгеле, мондый нәтиҗәләргә ирешү өлкәннәрнең фикер йөртүендәге үзгәртеп корулар белән бәйле, педагоглар һәм ата-аналар үзгәртеп коруда үзләре башлап йөрергә тиеш. Шунлыктан, Программа педагог-бала-ата-анамөнәсәбәтенә ориетлаштырылган.
Төркемнең эшчәнлеге төп гомумбелем бирү Программасының үтәлешенә юнәлгән һәм түбәндәге документларга нигезләнә:
-“Закон об образовании в Российской Федерации” (Принят 29 декабря 2012года № 273-ФЗ); -“Санитарно-эпидемиологическими требованиями к устройству, содержанию и организации режима работы дошкольных организацииях (Постановление от 15 мая 2013 года № 26 “Об утверждении СанПиН 2.4.1.3049-13);
-ПриказМинобразования Российской Федерации “Об утверждении Федерального государственного образовательного стандарта дошкольного образования” от 17.10.2013 № 1155;
-“Закон РТ № 44 от 28.07.2004г. “О государственных языках РТ и других языках в РТ”.
Төркемдә белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге түбәндәге программаларга яраклаштырып төзелгән:
-Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү Программасы “От рождения до школы» (под редакцией Н.Е.Веракса, Т.С.Комаровой, М.А.Васильевой Москва «Мозаика-Синтез», 2010;,

**Региональ компонент:**
- Закирова К.В. «Воспитание и обучение в детском саду». Программа обеспечивает организацию образовательной деятельности в татарских группах.

НРК буенча тәрбия һәм белем бирү бурычлары: балаларны Идел буе халыкларының (Россия, Татарстан) музыкасы, сәнгате, матур әдәбияты белән таныштыру.
Балаларда Идел буе халыклары культурасына кызыксыну уяту.
Ватанга, ана теленә патриотик хис тәрбияләү; туган телдә сөйләшәсе килү теләге тудыру.

- **РТ дәүләт телләренә өйрәтү:**
- Зарипова З.М. «Балалар бакчасында рус балаларына татар теле өйрәтү» программасы. «Идел-Пресс», 2013
- Гаффарова С. М. «Изучаем русский язык». Тәрбиячеләр өчен методик ярдәмлек. Методик тәкъдимнәр, эшчәнлек конспектлары, уеннар һәм күнегүләр, «Хәтер», 2011;
- Зарипова З.М. «Туган телдә сөйләшәбез». Балалар бакчасында татар төркемнәре өчен методик ярдәмлек.

Төркемнең төп эш юнәлеше икенче кече яшьтәге төркем балаларының танып-белү буенча күзаллауларын үстерүгә юнәлдерелгән. Балаларны табигать, сәнгать, нәфасәти эшчәнлекнең төрле төрләре белән таныштыру төрле юллар белән тормышка ашырыла. Төркемдә һәм саф һавада иҗади танып белү, интегральләштерелгән эшчәнлекләр, музыка белеме, мөстәкыйль эшчәнлек, шәхси эш эзлекле рәвештә алып барыла. Балаларны өйрәтүдә практик методлар (күзәтүләр, модельләштерү, тәҗрибәләр) киң кулланыла. Практик методлар белән бергә сүзле (аңлату, инструкция, җавап үрнәге, сораулар, бәя бирү), күрсәтмә методлар (предметлы, иллюстрацияле, схемалар) да урын алып тора, алар танып белү эшчәнлеген активлаштыруга булышлык итәләр. Нәтиҗәгә ирешү өчен уен методына караган эмоциональ алымнар бер-берсе белән тыгыз бәйләнеп, үрелеп бара.
**Максат:** Балаларны җәмгыять тормышы, әйләнә-тирәлек, табигать күренешләре белән таныштыру, актив сүзлеген баету, сөйләм телен үстерү.
**Бурычлар:**
**Үстерешле бурычлар:** - балаларның тере һәм тере булмаган табигатьнең үзара бәйләнеше турында белемнәрен киңәйтү, күзаллауны үстерү;
**Белем бирү бурычы**: - балаларда тирә-юньнең матурлыгын чынлыкта күрә белүне, дөньяви эстетик үсешне формалаштыру;
**Тәрбияви бурыч**: - балаларда рухи сыйфатлар тәрбияләү, табигатьне аңлый, саклый белергә, матурлыгына соклану хисе уяту.

**2. Эчтәлек бүлеге.**
**2.1 Уку елы өчен комплекслы – тематик планы**

| Вакыты | Бүлек исеме | Бурычлар | Йомгаклау чаралары |
|---|---|---|---|
| 2.09-6.09 | Безнең балалар бакчасы | Балалар бакчасы шартларына ияләштерү. Баланың социаль мохите буларак, балалар бакчасы (бакча бинасы һәм төркем бүлмәсендәге җиһазлар: шкаф, карават, уенчыклар) белән таныштыру. Балаларны бер-берсе һәм тәрбияче белән таныштыру. Балалар бакчасына йөрү, яшьтәшләре белән аралашуның балаларда уңай эмоцияләр тудыруларына ирешү. | Тәрбияченең адаптация бите тутыруы |
| 9.09-20.09 | Көз | Көз турында күзаллау формалаштыру; табигатькә, кешеләр киемендә, балалар бакчасы мәйданында сезонлы үзгәрешләр, уңыш җыю, кайбер яшелчәләр, җиләкләр, гөмбәләр турында беренчел күзаллау булдыру. Балаларның йорт хайваннары һәм кошлары турында белемнәрне киңәйтү. Көзен урман җәнлекләре һәм кошларының үз – үзләрен тоту үзенчәлекләре белән таныштыру. | Көзге яфраклар җыю һәм алар белән бүлмәне бизәү |
| 23.09-30.09 | Минем уенчыкларым | Иптәшләр белән дус, тату уйнау, уенчыкларны бүлешү, бер - береңә ярдәм итү кебек сыйфат-ларны тәрбияләү. Балалар бакчасына йөрү, яшьтәшләре белән аралашуның балаларда уңай эмоцияләр тудыруларына ирешү. | “Минем яраткан уенчык-ларым” исемле темага әңгәмә оештыру.<br>Уен “Уенчыклар кибетен-дә” |
| 1.10-4.10 | Безнең урман җәнлекләре | Туган як урман җәнлекләренә карата кызыксыну һәм сакчыл караш тәрбияләү; экологик тәрбия бирү; балаларга кыргый хайваннар, аларның тышкы билгеләре, үзенчәлекләре һәм файдалары турында белем бирү. | Д/уен “Кыргый хайванны тап?” |
| 7.10-11.10 | Гигиена | Балада, кеше буларак, үзе турында күзаллау булдыру, кеше гәүдәсенең төп өлешләре һәм аларның ни өчен кирәклеге белән таныштыру. Гәүдә өлешләренең атамалары хисабына балаларның сүзлеген активлаштыру. Балаларның үз-үзеңне чиста йөртү турында белемнәрен системалаштыру. Шапшаклык, җыйнаксызлык кебек<br>сыйфатларга тискәре мөнәсәбәт тәрбияләү. | Спорт уеннары уйнау.<br>“Сәламәт булыйк” дигән темага әңгәмә оештыру. |
| 14.10-25.10 | Минем гаиләм | Үз исемен, гаилә әгъзаларының исемнәрен белүләренә ирешү. Сөйләмдә ягымлы сүзләрне кулланырга өйрәтү, гаилә әгъзаларына ихтирам тәрбияләү. Нәрсәнең яхшы, нәрсәнең начар булуы, сәламәт тормыш образы турында башлангыч күзаллау булдыру. | “Минем гаиләм” темасына әңгәмә оештыру. |
| 28.10-8.11 | Мин кайда яшим? | Балаларны туган шәһәрләре (авыллары): аның исеме, объектлары (урам, йорт, кибет) һәм транспорт, һөнәрләр (табиб, сатучы, полиция хез-мәткәре) белән таныштыру, аларга карата кызыксыну уяту. Балаларны куркынычсызлык, юл йөрү кагыйдәләре турындагы белемнәрен тирәнәйтү. Урамнарга карата соклану хисе тәрбияләү. | “Минем шәһәрем” темасына әңгәмә оештыру. |
| 11.11-29.11 | Киемнәр | Өс киемнәре, аларның төсе һәм материалы белән таныштыру. Киемнәрне белдерә торган сүзләр хисабына сүзлекне киңәйтү һәм активлаштыру.<br>Киемнәргә карата сакчыл караш тәрбияләү. | Дидактик уен “Кием исе-мен ата”. |
| 2.12-6.12 | Мониторинг | | Балаларның персо-наль карточкала-рын тутыру |
| 9.12-31.12 | Яңа ел бәйрәме | Яңа елга һәм яңа ел бәйрәменә кагылышлы эшчәнлекне барлык төрен оештыру. Балаларда бәйрәм турында уңай эмоцияләр генә булдыру. | Яңа ел бәйрәмен уздыру.<br>Балалар иҗат күргәзмәсе |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 9.01-26.01 | Кыш | Кыш турында күзаллау формалаштыру (табигатьтә сезон үзгәрешләре, кешеләрнең киеме, балалар бакчасы мәйданы). Балаларны кар һәм аның үзенчәлекләре (ак төстә, эри, йомшак,салкын, җиңел) белән таныштыру. Кыш турында матур әдәбият әсәрләрен уку. | Уен “Салкын көннәр”<br>Балалар иҗат күргәзмәсе |
| 29.01-2.02 | Каникул. | | |
| 5.02-9.02 | Йорт хайваннары һәм кыргый хайваннар. | Йорт хайваннары һәм кыргый хайваннар турындагы белемнәрен киңәнтү, хайваннарның исемнәрен, хәрәкәтләрен әйтергә күнектерү һам аларның балалары белән таныштырып китү, рәсемнәрдән таба белү. Кыш көне урман җәнлекләре һәм кошларының үз – үзләрен тоту үзенчәлекләре белән таныштыру. Хайваннарга карта кызыксыну тәрбияләү. | Дидактик уен “Рәсемдә нәрсә сурәтләнгән?”<br>Балалар иҗат күргәзмәсе |
| 12.02-<br>22.02 | Әтием горурлыгым | Балаларда патриотик хисләр, ватанны саклаучыларга карата ихтирам, хөрмәт, бәйрәм рухы тәрбияләү. Балаларны әтиләр һөнәренә кагылышлы сюжетлы кечкенә рәсемнәр карарга, аларның эчтәлеген аңларга өйрәтү, эш-гамәлләрне белдерә торган сүз ләр хисабына балаларның сүзлеген активлаш-тыру;) төрле һөнәр кешеләренә һәм әтиләр хезмәтенә карата кызыксыну уяту. | Әтиләрне котлау |
| 25.02-7.03 | 8 март | Балаларда әниләргә карата хөрмәт, мәхәббәт хисләре тәрбияләү; балаларны – 8 март Халык – ара хатын кызлар бәйрәме белән таныштыру; әниләр хезмәтенә карата кызыксыну, хөрмәт тәрбияләү. | Әниләрне котлау |
| 11.03-<br>22.03 | Халык иҗаты | Балаларда халык иҗаты белән таныштыру. Халык авыз иҗаты (җырлар, бармак уеннары, биюләр, бәйрәмнәр, уенчыклар) белән таныштыру. Балалар эшчәнлегенең барлык төрләрен оештырганда, фольклор элементларын куллану. Балаларны халык иҗат иткән уенчыклар (матрёшкалар, дымка уенчыгы...) белән таныштыру; халык иҗатына кызыксыну, уенчыкларга (матрёшкага) карата сакчыллык тәрбияләү. | Уеннар күргәзмәсе оеш-тыру |
| 25.03-<br>22.04 | Яз | Яз турында күзаллау формалаштыру (табигатьтә сезон үзгәрешләре, кешеләрнең киеме, балалар бакчасы мәйданы). Язгы табигатькә карата сакчыл караш тәрбияләү; язгы табигатьнең матурлыгын тоя , билгеләрен күрә һәм аларны табигатьтә таба белергә өйрәтү. Яз көне урман җәнлекләре һәм кошларының үз – үзләрен тоту үзенчәлекләре белән таныштыру. | Яз бәйрәме |
| 22.04.-<br>30.04 | Мониторинг | | Балаларның персональ карточкаларын тутыру |
| 1.05-10.05 | Тиздән җәй җитә | Җәйге табигатькә карата сакчыл караш тәрбияләү; Җәйге табигатьнең матурлыгын тоя , билгеләрен күрә һәм аларны табигатьтә таба белергә өйрәтү | |
| 13.05-<br>17.05 | Үсемлекләр | Үсемлек дөньясына кызыксыну уяту. Бүлмәдәге гөлләргә, мәйданчыктагы җиргә чәчәкләр утырту, аларны тәрбияләүне аңлату,сөйләмне су сибү, чүп үләннәреннән арындыру кебек яңа сүзләр белән баету. | “Безнең мәйданчыкта нәр-сәләр үсә” танышу. |
| 20.05-<br>31.05 | Ямьле җәй | Җәй турында күзаллау формалаштыру (табигатьтә сезон үзгәрешләре, кешеләрнең киеме, балалар бакчасы мәйданы). Җәй көне урман җәнлекләре һәм кошларының үз – үзләрен тоту үзенчәлекләре белән таныштыру. Йорт хайваннары һәм кошлары, яшелчәләр, җиләк-җимешләр турында белемнәрен киңәйтү; табигатькә карата сакчыл караш тәрбияләү. | Җәй бәйрәме<br>Балалар иҗат күргәзмәсе |
| Җәйге чорда балалар бакчасы каникул режимында эшли. | | | |

**Гаилә белән үзара бәйләнеш.**

Хәзерге фән һәм практика баланың шәхесен формалаштыруда гаиләнеңуникаль роль уйнавын исбат итә. Беренче соңиальләшү гаиләдә башлана,баланың дөньяга, үзенә, башка кешеләргә карашы, мөнәсәбәте формалаша. Ата-аналарның кайгыртучанлыгы балада аның үз-үзенә ышанычын тудыра, башка кешеләр белән түземлек, үзара

хөрмәт принциплары нигезендә үзара мөнәсәбәткә керергә әзер торырга ярдәм итә.Ата-ананың тәрбия һәм белем бирү эшчәнлегендә катнашу мөмкинлеге булу бик зур әһәмияткә ия. Хәзерге заман балалар бакчасы ата-аналарга психологик һәм педагогик ярдәм күрсәтүче учреждение буларак та хезмәт итә. Шул ук вакытта гаилә дә үзара хезмәттәшлек итәр өчен педагогларны өзлексез үсешкә рухландыра.

Түбәндәге бурычларны үтәмичә, максатка ирешү мөмкин түгел:

-гаилә белән партнерлык мөнәсәбәте урнаштыру; -бакчада ата-анага бала тормышында катнашу өчен шартлар тудыру;

• бала тәрбияләүдә ата-аналарга психологик ярдәм күрсәтү;

• гаиләләр белән үзара аралашуда педагогик компетентлыкны өзлексез күтәрү.

**Гаилә белән үзара бәйләнеш принциплары.**

1.Психологик уңайлык (комфорт) принципы - ата-аналар белән аралашуда җылы атмосфера булдыру, һәр гаиләнең ихтыяҗын, социаль-психологик характеристикасын исәпкәалу. Ата-ана белән үзара ышанулы мөнәсәбәт ул - хөрмәт, диалогка омтылу, игътибарлылык, ихласлылык. Балага һәм аның якыннарына карата тәрбияченең игелеклелеге һәм ачыклыгы ата-ана ягыннан уңай кабул ителә. Ата - аналарның бакчада балалары шат булса, алар тәрбиячеләргә сораулар белән мөрәҗәгать итәләр. Ата-аналарның бала өчен балалар бакчасының уңайлы, куркынычсыз, файдалы булуын күрү генә түгел, ә балаларның үсешен күрүләре дә әһәмияткә ия. Тәрбияченең баланың яшь үзенчәлеген, психологиясен, үсеш кризисын белүе, ата-ананы тынычлындырып, кирәкле сүзләр таба белүе, алар белән ягымлы мөгаләмәдәге әңгәмәдәшче булуы мөһим.

2.Эшчәнлек принцибы.

Белем һәм тәрбия бирү процессында балалар бакчасы һәм ата-аналар арасындагы бәйләнештигез хокуклы партнерлар сыйфатына корылган. Партнерлык процессы катлаулы: танышу, җимерелүе һәм үзара аңлашу урнашу,бала тәрбияләүдә берүк максатны күздә тоту. Педагогның һәм балалар бакчасының позитив имиджы булуы мөһим.

3.Бербөтенлек принцибы -тәрбия һәм белем бирүдә гаилә һәм җәмгыять институтларының аерылгысыз бербөтен булуына нигезләнгән. Әлеге принцип бала тәрбияләүдә гаилә белән балалар бакчасының эш стратегиясен билгели. Җәмгыяти тәрбиянең нигезе ул - балага социаль таләпләр системасы кую. Ата-аналарның тәрбияви тәэсире булып, балага карата мәхәббәт, аны куркынычсызлык белән тәэмин итү, аны ничек бар шулай кабул итү тора.

4.Минимакс принцибы - һәр гаиләгә дифференциальякынкилү, ата-аналар белән эчтәлекле, тактлы аралашу. Ата-аналар белән танышкач, педагог һәр гаиләнең үзенчәлеген ачыклый, аларның активлыгын күтәрү өчен планлы

рәвештә шартлар тудыра.

5.Вариативлык принцибы - ата-аналарга тәрбия һәм белем бирү процессына кушылу һәм аралашуның формаларын тәкъдим итү: традицион һәм традицион булмаган, шәхси һәм төркемләп, дистанцион һәм кара-каршы аралашу.

6.Өзлексезлек принцибы өйдә һәм балалар бакчасында тәрбия бирүнең өзлексез баруын күз алдында тота.

7.Иҗадилык принцибы - тәрбия һәм белем бирү процессында барысына да иҗадилык күрсәтергә мөмкинлек ачу.

Ата-аналар белән үзара бәйләнеш формалары.

1.Мәгълүмати чаралар -(телдән журнал, реклама буклеты; балаларга тәрбия һәм белем бирү сораулары буенча мәгълүмати белешмә хезмәте; СМИ да чыгышлар; мәгълүмати кәрзиннәр, хатлар; күрсәтмә психо-педагогик пропаганда һ.б.)

2. Оештыру эшләре- (ата-аналар җыелышы; анкеталар тутыру; җәмгыяти ата- аналар оешмаларын төзү; коференцияләр, ата-аналар белән берлектә педсоветлар; брифинглар һ.б.)

3 .Культура-агарту чаралары - (ата-аналар мәктәбе; консультацияләр; тематик очрашулар; матур әдәбият буенча тематик күргәзмәләр оештыру; тренинглар; семинарлар; әңгәмә; дискуссияләр; ата-аналар кунакханәсе; түгәрәк өстәл һ.б.)

4. Оештыру-эшчәнлек - (ата-аналар белән берлектә үткәрелгән балаларның үсеш мониторингы, берләштерелгән ата-ана-бала проекты; күргәзмәләр; вернисажлар; мастер-класслар; балалар, педагоглар, ата-аналар иҗаты; гаилә портфолиосы ясау; иҗади эшчәнлек өчен табигый һәм ташландык материаллар җыю; балалар бакчасын ремонтлауда һәм яшелләндерүдә катнашу; балаларның бакчадагы тормышын сурәтләгән буклет, видеофильмнар әзерләү, журналлар чыгару;бакчада үткәрелгән чаралар турында фотоматериалларны электрон җибәрүдә булышу; үстерешле предметлы тирәлекнең сыйфатын тикшерүдә катнашу һ.б.)

5. Ата-аналарның педагогик процесста катнашуы - (ата-аналар катнашы белән шөгыльләр; балаларга әкиятләр уку; балалар белән төрле темага әңгәмәләр кору; ата-аналар катнашы белән сәхнәләштерү; саф һавада йөргәндә, экскурсияләргә барган балаларны озату; Ачык ишекләр, Сәламәтлек көнендә, Шәфкатьлелек марафонында катнашу һ.б.)

**Ата- аналарбелән үзара бәйләнеш формалары.**

1.Мәгълүмати чаралар -(телдән журнал, реклама буклеты; балаларга тәрбия һәм белем бирү сораулары буенча мәгълүмати белешмә хезмәте; СМИ да чыгышлар; мәгълүмати кәрзиннәр, хатлар; күрсәтмә психо-педагогик
пропаганда һ.б.)
2. Оештыру эшләре- (ата-аналар җыелышы; анкеталар тутыру; җәмгыяти ата- аналар оешмаларын төзү; коференцияләр, ата-аналар белән берлектә педсоветлар; брифинглар һ.б.)
3 .Культура-агарту чаралары - (ата-аналар мәктәбе; консультацияләр; тематик очрашулар; матур әдәбият буенча тематик күргәзмәләр оештыру; тренинглар; семинарлар; әңгәмә; дискуссияләр; ата-аналар кунакханәсе; түгәрәк өстәл һ.б.)
4. Оештыру-эшчәнлек - (ата-аналар белән берлектә үткәрелгән балаларның үсеш мониторингы, берләштерелгән ата-ана-бала проекты; күргәзмәләр; вернисажлар; мастер-класслар; балалар, педагоглар, ата-аналар иҗаты; гаилә портфолиосы ясау; иҗади эшчәнлек өчен табигый һәм ташландык материаллар җыю; балалар бакчасын ремонтлауда һәм яшелләндерүдә катнашу; балаларның бакчадагы тормышын сурәтләгән буклет, видеофильмнар әзерләү, журналлар чыгару;бакчада үткәрелгән чаралар турында фотоматериалларны электрон җибәрүдә булышу; үстерешле предметлы тирәлекнең сыйфатын тикшерүдә катнашу һ.б.)
5. Ата-аналарның педагогик процесста катнашуы - (ата-аналар катнашы белән шөгыльләр; балаларга экиятләр уку; балалар белән төрле темага әңгәмәләр кору; ата-аналар катнашы белән сәхнәләштерү; саф һавада
йөргәндә, экскурсияләргә барган балаларны озату; Ачык ишекләр, Сәламәтлек көнендә, Шәфкатьлелек марафонында катнашу һ.б.)

**Гаилә белән үзара бәйләнеш буенча эшәү планы.**

| Ай | Тема |
|---|---|
| сентябрь | • Ата-аналар белән оештыру җыелышы уздыру.<br>• Ата-аналардан "Әйдәгез танышабыз" дип аталган анкета тутырту.<br>• Ата-аналар өчен педагог-психолог, шәфкать туташының киңәшләре тупланган төрле папкалар булдыру.<br>• Туган көннәр (сентябрь аенда туучы балаларны котлау оештыру).<br>• Физкультура ОББЭ өчен форма булдыру. |
| октябрь | 1.Консультацияләр : “Хәрәкәтле уеннарның бала организмы өчен файдасы”, “Бишек җырлары җырлыйбыз”, “Яссытабанлылыкны кисәтү”, “Ни өчен бала уенчыкларны җыярга теләми?”, “Сәләтле бала”.<br>2. Газета “Сәламәт булыгыз!”, “Тәрбияче апа – бәйрәмең белән!”, “Өлкәннәрне тәбриклибез һәм бәйрәм белән котлыйбыз!”<br>3. Өлкәннәрне бәйрәм белән котлау, балаларның үз куллары белән ясаган бүләкләрен бирү.<br>4. “Сөмбелә” бәйрәмен уздыру<br>5. Табип киңәшләре: “Бабасыр”, “Балаланың гаиләдәге физик тәрбиясе”<br>6. Әти –әниләрне кызыксындырган сорауларга җавап бирү. |
| ноябрь | 1.Консультацияләр :“Профилактик прививкалар”, “Музыкотерапия”, “чиратта торганда һәм транспортта барганда балалар белән уеннар”.<br>2. Газета “Бәйрәм белән, кадерле әниләр!”<br>3. “Әниләр” бәйрәме уздыру<br>4. Табип киңәшләре: Матур һәм сәламәт тешләр”, “Төркемгә чир керсә...”<br>5. Әти –әниләрне кызыксындырган сорауларга җавап бирү.<br>6. Белешмәлек “Бала белән бергә уйныйбыз” |
| декабрь | 1.Консультацияләр : “Саф һавада йөрүнең файдасы”, “Әти –әни булу рәхәт ул”, “Сюжетлы-рольле уеннар аша балаларда туган телне үстерү”, “Өйгә уйный-уйный кайтабыз”.<br>2. Балалар өчен шугалак (тау) төзү.<br>3. Газета “Тәҗрибәләр үткәрәбез”, “Хуш киләсең, Яңа ел”<br>4. “Хуш киләсең, Яңа ел!” бәйрәме уздыру |

| | |
|---|---|
| | 5. Табип киңәшләре: “Салкын тиюдән саклану чаралары”, “Гәүдә төзелеше бозылуы”, “Саф һавада хәрәкәтле уеннар”<br>6. “Сюжетлы-рольле уеннар” күргәзмәсенә әзерлек һәм үткәрү.<br>7. Әти –әниләрне кызыксындырган сорауларга җавап бирү.<br>8. Ата – аналар җыелышы: “Тәртип кагыйдәләре” |
| январь | 1.Консультацияләр : “Бармак уеннары”, “Юл һәм балалар”<br>2. Газета “Балаларның юл травматизмы сәбәпләре”, “Чыныктыру чаралары”.<br>3. Ачык ишекләр көне: мастер – класс “Йокыдан уяну гимнастикасы”, “Саф һавада уеннар”<br>4. Мастер –класс “Сәламәт булыйк: чыныктыру алымнары”<br>5. Рәсем конкурсы “Айболит киңәшләре”<br>6. Табип киңәшләре: “Гриппка каршы аромотерапия”, “Туберкулездан саклану”, “Яссытабанлылык булса, нишләргә?”<br>7. Әти –әниләрне кызыксындырган сорауларга җавап бирү. |
| февраль | 1. Консультацияләр: “Ишетергә һәм тыңларга өйрәнәбез”. “Биибез дә, җырлыйбыз”<br>2. Газета “Изге Вәли көне”, “Бәйрәм белән әтием, абыем, бабам”<br>3. “Ватанны саклаучылар көне” бәйрәмен уздыру<br>4. Табип киңәшләре:“Отморожение», “Бала йокысы”, “Йокыдан уяну гимнастикасы”<br>5. Әти –әниләрне кызыксындырган сорауларга җавап бирү. |
| март | 1.Консультацияләр: “Тиктормас балаларга уеннар”, “Начар сүзлелек”, “Балаларның урамда уйнау җирлекләре”.<br>2. Рәсем конкурсы “Минем яраткан әкият героем”<br>3. “8март – халыкара хатын кызлар көне” бәйрәме уздыру<br>4. Табип киңәшләре: “Җил чәчәге авыруы”, “Авитаминоз”<br>5. Әти –әниләрне кызыксындырган сорауларга җавап бирү. |
| апрель | 1. Консультацияләр:«Витаминотерапия”, “Балалар алдыйлар”, “Беренче китаплар”.<br>2. Газета Бөек татар шагыйре Г.Тукай”<br>3. Табиб киңәшләре: “Тычканнар таратучы чирләр”, “Саф һавада йөрү бик файдалы”<br>4. Әти –әниләрне кызыксындырган сорауларга җавап бирү. |
| май | 1.Консультацияләр: “Кояш, су һәм һава безнең дуслар”, “Балаларның җәйге ялы”, “Су белән уеннар”.<br>2. Газета “Без сезне мәңге онытмабыз!”<br>3. Рәсем конкурсы “Җиңү көне белән!”<br>4. Табип киңәшләре: “Талпан авыруы”, “Баланың күзләрен саклыйк”<br>5. Әти –әниләрне кызыксындырган сорауларга җавап бирү.<br>6. Ата – аналар җыелышы. |

**2.3 Җәмгыять белән хезмәттәшлек.**

| **Юнәле** | **Оешма исеме** | **Хезмәттәшлек формасы** | |
|---|---|---|---|
| **Белем бирү** | НГПУ | Квалификацияне күтәрү курслары, смотрларда, конференцияләрдә, күргәзмәләрдә катнашу | План буенча |
| | Мәктәпкәчә яшьтәге шәһәр оешмалары | Методик берләшмәләр, консультацияләр, методик очрашулар, тәҗрибә бүлешү. | Оешма планы буенча |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Шәһәр күләм балалар һәм яшьләр өчен күргәзмәләр ДЮЦ №14 | Күргәзмә, конкурсларда катнашу. | Еллык план буенча |
| **Меди цина** | 3 нче балалар хастәханәсе | - Медицина тикшеренүләр үткәрү;<br>- Профилактика һәм авырулар буенча консультация | Кирәк булганда |
| **Культура** | Театраль коллективлар | Балалар бакчасында театр күрсәтү | Ел дәвамында |
| | “Огниво”,<br>“Кызыл тау” үзәге | Күргәзмәләрдә, смотр- конкурсларда катнашу. | Ел дәвамында |
| **Куркынычс ызлык** | Янгын чыгу куркыныч- сызлыгы | Экскуцияләр, янгын сүндерү хезмәткәрләре белән очрашу, янгын чыгу куркынычсызлыгы буенча конкурслар, консультация, инструктаж | План буенча |
| | ГИБДД | Балалар белән юл йөрү кагыйдәләре буенча әңгәмә, күргәзмә һәм конкурсларда катнашу. | Еллык план буенча |
| **СМ И** | СМИ | “Көмеш кыңгырау”- газетасы, эш тәҗрибәсен бхлешү;<br>Тәрбиячеләрнең үз белемнәрен бүлешү методикасы. | Кирәк чакта |
| **Экол огия** | Экология һәм табигатне саклау музее | Күмәк күргәзмәләр оештыру | План буенча |

## 3.Оештыру бүлеге.

### 3.1 Материаль- техник тулыландыру

| **Белем бирү программасының юнәлеше** | **Төркем бүлмәсе,кабинетлар, җиһазлар исемлеге** |
|---|---|
| Программа дошкольного образования «От рождения до школы» под редакцией Н.Е. Вераксы, Т.С. Комаровой, М.А. Васильевой, основная, (грамота, развитие речи, ФЭМП, ознакомление с художественной литературой, ознакомление детей с природой, логическое мышление, ИЗО деятельность, исследовательская, конструктивная деятельность) | Төркем бүлмәсе ,җиһазлар исемлеге , стәлләр, урындыклар, дидактические игры, с/р уеннар өчен уен- модульләр, китаплар, үстерешле плакатлар, уеннар,<br>төзелеш өчен конструктор, эксперимент почмагы, йомшак модульләр, таратма материал; матур әдәбият, өлкәннәр өчен педагогик литература, персонаж-уенчыклар. |
| Программа дошкольного образования «Изобразительная деятельность в детском саду» под редакцией Т.С. Комаровой, основная (рисование, лепка,<br>конструировании | Төркем бүлмәсе . Җиһазлар исемлеге, дидактик уеннар, игровые модули для сюжетно-ролевой игры, китаплар, уеннар, үстерешле плакатлар,төзелеш өчен конструктор, эксперимент өчен почмак, йомшак модульләр, таратма, күрсәтмә материал, матур әдәбият, зурлар өчен педагогигик әдәбият, уенчык-персонажлар. |
| Программа дошкольного образования «Основы безопасности жизнедеятельности. Төркем бүлмәсе. Җиһазлар исемлеге. Өстәлләр, урындыклар, дидактик уеннар, сюжетно-рольле уеннар өчен модульләр,<br>китаплар, уеннар, үстерешле плакатлар, 50 дошкольников» под редакцией Н.Н. Авдеевой О.Л. Князевой, Р.Б. Стеркиной, основная (ОБЖ) | Төркем бүлмәсе Җиһазлар исемлеге<br>Өстәлләр, урындыклар, дидактик уеннар, сюжетно-рольле уеннар өчен модульләр, китаплар, уеннар, үстерешле плакатлар, 50 дошкольников» под редакцией |

| | |
|---|---|
| | Н.Н. Авдеевой О.Л. Князевой, Р.Б. Стеркиной, основная (ОБЖ) төзелеш конструкторы, эксперимент почмагы, йомшак модульләр, таратма материал, урам, бакча, шәһәр макеты,торак йортлар, юл билгеләре,төзелешләр, ландшафт схемасы белән келәм, персонаж- уенчыклар. |
| Программа дошкольногообразования «От рождения до школы» под редакцией Н.Е. Вераксы, Т.С. Комаровой, М.А. Васильевой, основная (музыкальное). Программа дошкольного образования «Камертон» под редакцией Э.П. Костиной, (музыкальное) | Музыка залы. Җиһазлар исемлеге. Пианино, театр төрләре, телевизор, музыкальный центр, набор шумовых музыкальных инструментов, музыка инструментлары җыелмасы, дидактик уеннар һ.б. |
| Программа дошкольного образования «Театр - творчество - дети» под редакцией Н.Ф. Сорокиной, основная (театральная деятельность). | Музыка залы. Җиһазлар исемлеге. Пианино, театр төрләре, телевизор, музыкальный центр, музыкаль инструментлар җыелмасы, дидактик уеннар һ.б. |

### 3.2 Программа һәм методика белән тәэмин итү

**Нормативно-правовые документы:**
- Конвенция о правах ребенка.
- Конституция РФ
-Федеральный закон «Об образовании в Российской Федерации»; от 29.12.2012 № 273-ФЗ
- Федеральный государственный образовательный стандарт дошкольного образования (Утвержден приказом Министерства образования и науки Российской Федерации от 17 октября 2013 г. N 1155);
-«Порядок организации и осуществления образовательной деятельности по основным общеобразовательным программам – образовательным программам дошкольного образования» (приказ Министерства образования и науки РФ от 30 августа 2013 года №1014 г. Москва);
- Санитарно-эпидемиологические требования к устройству, содержанию и организации режима работы дошкольных образовательных организаций» (Утверждены постановлением Главного государственного санитарного врача Российской Федерации от 15 мая 2013 года №26 «Об утверждении САНПИН» 2.4.3049-13);
-«Закон РТ №44 от 28.07.2004г. «О государственных языках РТ и других языках РТ»;

| Белем бирү өлкәләре | Үсешнең төп юнәлешләре | Эшчәнлек Төре | Кулланылган программалар, методик әсбаплар |
|---|---|---|---|
| Социаль коммуника тив үсеш өлкәсе | Әхлакый кыйммәтләр. Хезмәт. Куркынычсызлык | Уенга өйрәтү. Социаль үсеш Хезмәт тәрбиясе Хуҗалык-көнкүреш ОБЖ | **Төп әдәбият:** Т.С. Комарова, Л.В. Куцакова, Л.Ю. Павлова «Трудовое воспитание в детском саду». Программа и методические рекомендации. - М.: Мозаика - Синтез, 2009. **Өстәмә әдәбият:**1.Л.В. Куцакова «Конструирование и ручной труд в детском саду». Программа и методические рекомендации. –М.: Мозаика – Синтез, 2009. 2.Р. Ш. Ахмадиева, Е.Е . Воронина, Д..М. Мустафин,. «Обучение детей дошкольного возраста правилам безопасного поведения на дорогах» Методические рекомендации. - М.: Мозаика - Синтез, 2010 |
| Танып белү үсеш өлкәсе | Иң гади Математик күзаллау Әйләнә-тирә | Сенсорик үсеш Иң гади математик күзаллауны формалаштыру Тирә-юнь белән таныштыру | **Төп әдәбият:** 1. "Математикага өйрәнәбез". Икенче кечкенәләр төркеме: Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре өчен эксперименталь методик әсбап / З. Г. Шәрәфетдинова И.Җ. Хәбибулина, Ф.В.Хәзрәтова.— Казан: 2010.—130 б.— «Поликультуралы белем бирү моделе» сериясе **Өстәмә әдәбият:** 1. И.А. Помораева, В.А. Позина «Занятия по формированию элементарных математических представлений в старшей группе детского сада». Планы занятий. - М.: Мозаика - Синтез, 2010. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | 2. Математика в детском саду. Рабочая тетрадь для детей. М.: Мозаика-Синтез, 2011.<br>3. Л.В. Куцакова «Занятия по конструированию из строительного материала в младший группе детского сада». Конспекты занятий. - М.: Мозаика -Синтез, 2010.<br>4. Бурганова Р. А. “Знакомство с природой родного края”.<br>5. О.А. Дыбина «Ребенок и окружающий мир». Программа и методические рекомендации. - М.: Мозаика - Синтез, 2010. Е. В. 6. Колесникова “Математика для детей 3-4 лет”. М.: ТЦ Сфера, 2015.- 56 с. (математические ступеньки). |
| Нәфасәти-<br>Сәнгать үсеш<br>өлкәсе | Продуктив<br>эшчәнлек<br>Музыка тәрбиясе | Рәсем<br>Әвәләү<br>Кисеп ябыштыру<br>Кул эше<br>Конструкцияләү<br>Музыка тәрбиясе<br>Сәхнәләштерү | **Төп әдәбият:** Зиннатова **Р**. М . Сурәтләү эшчәнлеге һәм конструкцияләү. Икенче кечкенәләр төркеме: Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре өчен экспериментал ь методик кулланма / Р. М. Зиннатова, Л. Ә. Гарәева, А. Г. Зворыкина. — Казан: Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты, 2010. - 144 б. - «Поликультуралы белем бирү моделе» сериясе.<br>**Өстәмә әдәбият:** 1.Комарова. Т.С. Изобразительная деятельность в детском саду. Программа и методические рекомендации. М.: Мозаика-Синтез, 2010.<br>2.И.А.Лыкова.Программа художественного воспитания,обучения и развития детей 2-7 лет «Цветные ладошки».<br>3.М. Б. Зацепина «Музыкальное воспитание в детском саду». Методическое пособие. - М.: Мозаика-Синтез, 2010 М. Б.Зацепина, Т.В.Антонова "Народные праздники в детском саду". Методическое пособие. - М.: Мозаика-Синтез, 2010.<br>МРК<br>1.«Күрсәтәле,үскәнем" З. Г. Ибраһимова, З.Р.Гыйләҗетдинова, Ф.Җ.Җәләлетдинова - Казан: Мәгариф,2010г.<br>2. Әй уныйбыз, уйныйбыз. Л. Н. Шәйдәева, Р. Ә. Кадыйрова. З. Ф. Бәдретдинов.<br>3.Үстерешле уеннар. К.З.Закирова,Р.Э.Кадыйрова. -<br>Казан: Магариф,2013г |
| Сөйләм<br>үсеше | Сөйләм<br>телен<br>Үстерү Матур<br>әдәбият<br>Уку | Матур<br>әдәбият<br>белән таныштыру | **Төп әдәбият:** В.В. Гербова «Занятия по развитию речи во второй группе детского сада». Планы занятий. - М.: Мозаика - Синтез, 2011.<br>**Өстәмә әдәбият:** 1.Иң матур сүз. Ата-аналар һәм балалар бакчасы тәрбиячеләре өчен хрестоматия. – Казан: Мәгариф, 2000.<br>2. Кахыйханова. В. С., Зарипова К. М. “Туган телем- бөек анам”.<br>3. Хазратова Ф.В. «Туган телдә сөйләшәбез» Методическое пособие для воспитателей татарских групп ДОУ 3 - 4 лет.<br>4. Закирова К.В. «Балачак аланы». Хрестоматия для воспитателей и родителей.<br>5. Кашапова М.Ф. «Уйныйк эле, балалар» метод.рекомендации (первая книга)<br>6. Үз илемдә, үз телемдә: Логопедлар, тәрбиячеләр һәм укытучылар өчен методик кулланма / Ф.М. Зиннурова. – Казан: Мәрариф, 2009. |
| Физик<br>тәрбия<br>үсеше | Здоровый<br>образ<br>жизни<br>движения | Физик культура<br>Төп хәрәкәтләр<br>Спорт күнегүләре<br>Спорт уеннары<br>Хәрәкәтле уеннар<br>Физкультура<br>сәламәтләндерү<br>эшчәнлеге культура-<br>гигиена күнекмәләре | Степаненкова Э.Я. Физическое воспитание в детском саду. - М.: Мозаика-Синтез, 2010.<br>Л.И. Пензулаева «Физическая культура в детском саду». Вторая младшая группа. - М.: Мозаика - Синтез, 2012.<br>Пензулаева Л.И. Оздоровительная гимнастика для детей 3-7 лет. - М: Мозаика-Синтез, 2010<br>**МРК**<br>**Өстәмә әдәбият:** 1.К.В Закирова "Уйный уйный үсәбез" "Мәгариф" нәшрияты, Казан . 2005 ел |

### 3.3 Үстерешле предметлы тирәлек

1.Үстерешле предметлы тирәлек балаларның яшь үзенчәлекләрен һәм үсешләрендә коррекцион җитешмәүчәнлеге булган балаларны исәпкә алып, аларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту өчен төркемдә һәм балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү процессын максималь тормышка ашыра.

2.Үстерешле предметлы тирәлек балалар белән өлкәннәрнең аралашу мөмкинлеге, бердәм эшчәнлеге, балаларның хәрәкәт активлыгы, шулай ук аларның ялгыз калу мөмкинлеге белән тәэмин итә.

3.Үстерешле предметлы тирәлек:

-төрле тәрбия һәм белем бирү программаларын тормышка ашыруны;

-милли культура, климат шартларын;

-балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алырга тиеш.

4.Үстерешле предметлы тирәлек бай эчтәлекле, үзгәрүчән, күпфункцияле, вариатив, аңлаешлы һәм куркынычсыз булырга тиеш.

Предметлы тирәлек белән тулыландыру тәрбия һәм белем бирү процессының бербөтенлек принципына, ФДББС буенча балаларның психологик һәм шәхси үзенчәлекләренә, материалларның үзенә хас үзгәрүчән уеннар, дидактик материаллар белән тәэмин ителүенә, балалар белән өлкәннәрнең интегральләштерү принципына, балаларның уен, хәрәкәт активлыгы, эзләнү, тәҗрибә, конструктив, матур әдәбиятны кабул итү һәм коммуникатив эшчәнлегенә Кулланылган материалларның һәм җиһазларның сыйфат сертификатлары бар,һәм алар гигиена, педагогик, эстетик таләпләргә җавап бирә алалар.

### 3.4. Сәламәтләндерү чаралары.

Ел дәвамында медицина хезмәткәрләре җитәкчелегендә, балаларның сәламәтлекләрен, җирле шартларны исәпкә алып, һава, кояш, су кебек табигый факторларны файдаланып, төрле комплекслы чыныктыру чаралары оештыру.

Балаларны бина эчендә җиңелчә киенеп йөрергә күнектерү. Көндәлек режимга туры китереп озаклап һавада йөртү.

Хәрәкәтле уеннар һәм физик күнегүләр белән кызыксынучанлыкларын үстерү, уеннарда катнашасы килү теләге булдыру.

Чыныктыру чаралары үткәргәндә һәр балага, сәламәтлек торышын истә тотып, шәхси якын килү.

Махсус чыныктыру чараларын, әти-әниләрнең теләкләрен искә алып, медицина хезмәткәрләре һәм администрация карары нигезендә уздыру.

### 3.5. Традицион вакыйгалар, бәйрәмнәр, чаралар

Күңел ачу чаралары, бәйрәмнәр - һәр балага төркем бүлмәсендә, урамда иректе уеннар уйнарга, парк, шәһәр урамы буйлап сәяхәт кылырга, актив һәм пассив ял итәргә мөмкинлек, эмоциональ тынычлык бирә, баланың үзенә шөгыль таба белү сәләтен формалаштыра.

Икенче кечкенәләр төркемендә бәйрәмнәр һәм күңел ачуларны тематик планлаштыру.

| № п/п | Бәйрәм исеме | Үткәрү вакыты | Бәйрәмгә хәзерлек |
|---|---|---|---|
| 1 | «Исәнме көз» | Сентябрьнең 4нче атнасы | Көзге табигать,көзге урманга хас күренешләрне күзәтү<br>-картиналар кару<br>-әңгәмә,сөйләшүләр<br>-жырлар,биюләр,шигырьләр өйрәнү<br>-яфраклар жыеп киптерү |
| 2 | «Бакчада» (күңел ачу кичәсе) | Октябрьнең 4нче атнасы | -яшелчә,җиләк-җимешләрне танып белергәөйрәтү<br>-аларны рәсемдә чагылдыру<br>-олылар хезмәте турында сөйләү<br>-җыр-биюләр өйрәнү<br>-яшелчә һәм жиләк-жимеш маскалары ясаганда катнашу |
| 3 | «Теремкәй» (театрльләшкән уен) | Ноябрьнең<br>2нче атнасы | Әкият геройлары катнашында күңел ачуларда катнаша башлауларына ирешү |
| 4 | Яна ел бәйрәме | Декабрьнең 4нче атнасы | -кышкы табигатьне күзәтү<br>-кар бөртекләре ясау |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | -жырлар,биюләр өйрәнү<br>-рәсемнәр карау<br>-әңгәмә,сөйләшүләр |
| 5 | «Маша һәм аю» (театрльләшкән күңел ачу) | Гыйнварның 3нче атнасы | Әкиятләрне караганада түземлелек тәрбияләү,экият барышын аңлауларына ирешү. |
| 6 | Ватанны саклаучылар көне | Февральнең 3нче атнасы | -әтиләр турында сөйләшү<br>-аларны кунакка чакыру<br>-шигырьләр,жырлар өйрәнү |
| 7 | «Бүре һәм кәҗә бәтиләре» (театрлашкан уен) | Февральнең 2нче атнасы | Әкият геройлары катнашында күңел ачуларда катнаша башлауларына ирешү |
| 8 | Әниләр бәйрәме | Мартның 1нче атнасы | -әниләр турында сөйләшү<br>-жырлар,шигырьләр өйрәнү<br>-әниләр пешергән ризыклар белән бәйрәмнән соң сыйлану |
| 9 | Яз бәйрәме | Мартның соңгы атнасы | -язгы күренешләрне күзәтү<br>-рәсемнәр,иллюстрацияләр карау<br>-шигырьләр,җырлар өйрәнү |
| 10 | «Язгы урманда» (кунел ачу) | Апрельнең 1нче атнасы | -урманда яшәүче хайваннарның яшәүләре,тышкы кыяфәтләре, тавышлары турында сөйләшү<br>-уеннар уйнау<br>-җырлы-биюле уеннар |
| 11 | «Әбиемдә кунакта» | Апрель ахыры | -йорт хайваннары белән танышуны дәвам итү<br>-алар турында жырлар,биюләр өйрәнү |
| 12 | Әй су ага,су ага» (күңел ачу) | Майның 2нче атнасы | Су турында тизәйткечләр, әйтемнәр,шигырьләр,жырлар өйрәнү |
| 13 | Исәнме җәй (бәйрәм) | Майның соңгы атнасы | -җәй турында сөйләшү.<br>-елга,урман,җәйге табигать турында картинкалар карау<br>-рәсем ясау<br>-жырлар,шигырьләр өйрәтү |

**Кушымта.**

**Аралашу (сөйләм телен үстерү)**

| **Ай** | **№** | **Тема** | **Максат** |
|---|---|---|---|
| С<br>Е<br>Н<br>Т<br>Я<br>Б<br>Р | 1. | Минем яраткан уенчыкларым | Исем, Сыйфат кулланып гади җөмләләр төзергә өйрәтү. Уенчыкларга сакчыл караш тәрбияләү. (Казыйханов В.С. Зарипова К.М. 34 бит) |
| | 2. | Исәнме бакча! Балалар белән танышу. | Танышу. Син кем? Синең исемең ничек? Сорауларына җавап алу. Балаларны тәрбияченең сөйләмен аңлый белергә өйрәтү. Сүз байлыгын арттыру. ( Закирова К. В. 6 бит) |
| | 3. | Көз килде. | Балаларны рәсем карарга өйрәтү. Тәрбияче куйган сорауга аңлы рәвештә җавап бирүләренә ирешү. Рәсем буенча хикәя төзеп сөйләү теләге уяту. (Казыйханов В.С. Зарипова К.М.36 бит) |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Ь | 4. | Яшелчә бакчасында. | Өйрәнеленгән яшелчә исемнәрен дөрес һәм аңлаешлы итеп әйтелүләренә ирешү. Сыйфатлары буенча яшелчәләрне табу. Балаларда узара дустанә мөнәсәбәт тәрбияләү. (Казыйханов В.С. Зарипова К.М.39 бит) |
| ОКТЯБРЬ | 1. | Кыргый хайваннар. | Балаларның кыргый хайваннар турында белемнәрен ныгыту, аларның кайда яшәүләре, нәрсәләр белән тукланулары турында аңлату. (Закирова К.В.108 бит) |
| | 2. | Сәламәтлек – зур байлык | Балаларның үз- үзеңне чиста йөртү турында белемнәрен системалаштыру. Табышмаклар, проблемалы сораулар нигезендә балаларның фикер йөртү сәләтен үстерү. Шапшаклык, җыйнаксызлык кебек сыйфатларга тискәре мөнәсәбәт тәрбияләү. (Казыйханов В.С. Зарипова К.М.50 бит) |
| | 3. | Безнең гаилә | Балаларга гаилә әгъзаларының исемнәрен өйрәтүне дәвам итү. Яңа сүзләр исәбенә сүз байлыгын арттыру. Якын кешеләренә карата хөрмәт, ярату хисләре тәрбияләү. (Казыйханов В.С. Зарипова К.М.40 бит) |
| | 4. | Безнең шәһәр. | Балаларны туган шәһәр, аның исеме белән таныштыру, юл йөрү кагыйдәләре турында элементар белемнәр бирү, аңга алуларын, диалогик сөйләмнәрен үстерү, туган шәһәр белән горурлану хисе тәрбияләү. (Хәзрәтова Ф. В. “Туган телдә сөйләшәбез” методик кулланма, 38 бит) |
| НОЯБРЬ | 1. | Яраткан машиналарыбыз | Төрле машиналарның атамалары исәбенә сүз байлыгын үстерү. Балаларны теге яки бу эш хэрэкәтенең кем тарафыннан башкарылуына караган сорауларны аңлый белергә һәм дөрес җавап бирергә өйрәтү. (Казыйханов В.С. Закирова К.В 24 бит) |
| | 2. | Шифаханә | Табиб һөнәре турындагы белемнәрне үстерү. Диалогик сөйләм күнекмәләрен үстерү. Образлы фикер йөртү сәләтен арттыру. Ягымлы сүзләрне сөйләмдә куллануны активлаштыру. (Казыйханов В.С. Закирова К. В.51 бит) |
| | 3. | Киемнәр. | Өс киемнәрен һәм предметларны билгеләре буенча төркемнәргә бүлергә өйрәтү. Балаларда чисталык, пөхтәлек тәрбияләү. Үз киемнәрен төреп яки элеп куярга гадәтләндерү. (Зарипова К.М.84 бит) |
| | 4. | Яңа курчак белән танышу | “Киемнәр” темасына караган сүзләрне ныгыту. Образлы фикер йөртү сәләтен үстерү. Балаларда курчак уйнау теләге булдыру. (Казыйханов В.С. Закирова К.В 47 бит) |
| | 5 | Курчакны урамга алып чыгу | Курчакны урамга киендерү. Балаларда уен барышын кузаллаулау сәләтен булдыру. Курчакта алар кебек киенә белә, аның да урамга, саф һава суларга чыгасы килә. (Закирова К.В.17 бит) |
| ДЕКАБРЬ | 1. | “Аваз культурасы өстендә эш” | А, ә авазларын дөрес артикуляөия белән әйтә белү күнекмәләрен булдыру, бу авазлар кергән сүзләр әйттерү, тавыш көче өстендә эш. (Закирова К.В. 7 бит) |
| | 2. | “Аваз культурасы өстендә эш” | **У** һәм **ү** авазларын артикуляөия билгеләре буенча аерырга өйрәтү. Авазларны активлаштыру. Фонематик ишетү сәләтен үстерү. (Казыйханов В.С. Закирова К.В 35 бит) |
| | 3. | “Тылсымлы” таякчык | Балаларны сузык һәм тартык авазларны, аерым сүзләрне ачык итеп әйтергә өйрәтү. Төсләр турындагы кузаллауны ныгыту, төс белдерә торган сыйфатларны активлаштыру. |
